РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ» ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ГЛАВА ГОРОДА ЧИСТОПОЛЬ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 19 апреле** **Чистай шәһәре** **№3**

Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре башлыгының «Гражданнар муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучылар һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230 номерлы Федераль закон нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Гражданнар муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучылар һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган «Гражданнар муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучылар һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның «в» пунктчасында һәм 13 пунктта «акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар)» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында /http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

Чистай шәһәре
башлыгы Д.А. Иванов